СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2022 г. Заинск № 88

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 24 статьяның 4 пункты 4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.1. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре; җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары:

| **Рөхсәт ителгән** | **Рөхсәт ителгән файдалану төренең** | **Җир кишәрлекләренең чик күләме һәм рөхсәт ителгән төзелешнең һәм капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары** |
|---|---|---|

| файдалану төренең коды* | аталышы * | жир кишәрлеге күләме | катларның чик саны һәм төзелешнең чик биеклеге | төзелешнең максималь проценты | жир кишәрлекләре чикләреннән минималь ара |
|---|---|---|---|---|---|
| **Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре** | | | | | |
| 2.5 | Уртача катлы торак төзелеше | билгеләнми | Төп төзелеш катларының чик саны – 8 (мансардны да кертеп);<br>Төп төзелешнең чик биеклеге – билгеләнми;<br>Коймаларның максималь биеклеге - 1 м. | 40 % | 5 м.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында араны киметү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру рөхсәт ителә. |
| 2.6 | Күпкатлы торак төзелеше (бик биек төзелеш) | билгеләнми | Төп төзелеш катларының чик саны – 20 (мансардны да кертеп);<br>Төп төзелешнең чик биеклеге – билгеләнми;<br>Коймаларның максималь биеклеге - 1 м. | 40 % | 5 м.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында араны киметү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру рөхсәт ителә. |
| 3.5.1 | Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү | билгеләнми | билгеләнми | 80 % | 5 м.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында араны киметү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру рөхсәт ителә. |
| 12.0 | Гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләр) | билгеләнми | | | |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре** | | | | | |
| 2.7 | Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 2.7.1 | Гараж билгеләнешендәге объектлар | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** | | | | | |
| 2.1 | Шәхси торак төзелеше өчен | минималь - 600 кв. м; максималь - 5000 кв. м. | Төп төзелеш катларының чик саны – 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1;<br>Төп төзелешнең чик биеклеге – 10 м; ярдәмче корылмаларның – 3,5 м (яссы түбә белән), 4,5 м (авыш түбә белән, биеклек конекта).<br>Коймаларның максималь биеклеге– 2,0 м. | 20 % | урам-юл челтәренә чыга торган җир кишәрлеге яклары өчен - 3 м; җир кишәрлегенең башка яклары өчен - билгеләнмәгән.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында араны киметү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру рөхсәт |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ителә. |
| 2.1.1 | Аз катлы күп фатирлы торак төзелеше | минималь - 400 кв. м.; максималь - билгеләнми | Төп төзелеш катларының чик саны – 4 (мансардны да кертеп);<br>Төп төзелешнең чик биеклеге – 15 м;<br>Коймаларның максималь биеклеге– 1,0 м. | 40 % | 5 м.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында араны киметү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру рөхсәт ителә. |
| 2.3 | Блоклы торак төзелеше | минималь - 300 кв. м; максималь - 1000 кв. м. | Төп төзелеш катларының чик саны – 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1;<br>Төп төзелешнең чик биеклеге – 10 м; ярдәмче корылмаларның – 3,5 м (яссы түбә белән), 4,5 м (авыш түбә белән, биеклек конектан).<br>Коймаларның максималь биеклеге– 2,0 м. | 30 % | урам-юл челтәренә чыга торган җир кишәрлеге яклары өчен-3 м; җир кишәрлегенең башка яклары өчен - билгеләнмәгән.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында араны киметү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру рөхсәт ителә. |
| 4.9.1 | Юл буе сервисы объектлары | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми | билгеләнми |
| 8.3 | Эчке тәртипне тәэмин итү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |

».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының җир мәсьәләләре, экология һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә (Р.В. Әгъләмов) йөкләргә.

**Совет Рәисе урынбасары** **Е.В.Недошивина**